БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
11 сентябрь 2025 ел

**КАРАР**
№ 340

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар кылды:

1. Балтач район Советының 2015 елның 11 августындагы 294 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (2018 елның 1 ноябрендәге 149 номерлы, 2022 елның 7 июнендәге 132 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетаны;»

1.2. 3.6. пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.6.10 пункты өстәргә:

«3.6.10. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетаның аңа билгеле булган белешмәләрендәге үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиленең карары буенча үзгәртелгән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).;

1.3. 1 нче кушымтаның 12 пунктындагы 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ рәвешендә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль район башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин